**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 декабрь № 885

г. Казань

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурсны (алга таба – Конкурс) ел саен үткәрү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне расларга (карага теркәләләр):

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмә (алга таба – Конкурс турында нигезләмә);

Конкурсны үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Конкурс турында нигезләмә нигезендә Конкурс үткәрүне оештыруны тәэмин итәргә.

4. Конкурсны үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслау тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге максатларга күздә тотылган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\885.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурсны (алга таба – Конкурс) оештыручы (алга таба – Оештыручы) булып Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы тора.

1.2. Конкурс ел саен үткәрелә.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – Татарстан Республикасының СЮ КБО) эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга игътибарны җәлеп итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

Татарстан Республикасында эшләп килә торган Татарстан Республикасының СЮ КБО халык арасында популярлаштыруга массакүләм мәгълүмат чараларын (алга таба – ММЧ) стимуллаштыру;

Татарстан Республикасының СЮ КБО тарафыннан үткәрелә торган чараларга һәм акцияләргә багышланган телевидениедә, радиода, басма ММЧ һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге материаллар санын арттыру;

Татарстан Республикасының СЮ КБО тарафыннан үткәрелә торган эшчәнлекне яктырта торган журналистлар эшләренең сыйфатын күтәрү.

## 3. Конкурсның өстенлекле юнәлешләре

3.1. Өстәмә белем бирүне, фәнни-техник һәм сәнгати иҗатны үстерү.

3.2. Социаль ятимлекне профилактикалау, гаиләгә, әни булуга, әти булуга һәм балачакка булышлык күрсәтү.

3.3. Ирекле янгын саклыгының гамәлдәге бүлекчәләрен үстерү һәм камилләштерү, табигый бәла-казалар, экологик, техноген һәм башка һәлакәтләр китергән зыянны җиңеп чыгуга, бәхетсезлек очракларын булдырмый калуга халыкны әзерләү.

3.4. Өлкән яшьтәге кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрү.

3.5. Гражданнар бердәмлеген ныгыту һәм милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне җайлаштыру.

3.6. Инвалидлар һәм аларның гаиләләренең социаль җайлашуы, инвалидларның, шул исәптән мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның эшкә урнашуына, эш урынында җайлашуына һәм беркетелүенә булышлык күрсәтү.

3.7. Әйләнә-тирә мохитне саклау, балаларның һәм яшьләрнең экология өлкәсендәге эшчәнлеген үстерү.

3.8. Җәмгыятьтә коррупциячел тәртипкә түзмәү формалаштыру.

3.9. Массакүләм спортны үстерү һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру.

3.10. Гражданнарның үз-үзләрен тотышында социаль яктан куркыныч формаларны профилактикалау.

3.11. Хәйриячелеккә һәм ирекле эшчәнлеккә булышлык күрсәтү.

3.12. Татарстан Республикасының СЮ КБО секторы инфраструктурасын үстерү.

## 4. Конкурс номинацияләре

4.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы телесюжет (яки телетапшыру)»;

«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы радиосюжет (яки радиотапшыру)»;

«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча басма массакүләм-мәгълүмат чараларында иң яхшы язма»;

«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә иң яхшы язма».

4.2. Һәр номинация буенча I, II, III урыннар бирү күздә тотылган.

## 5. Конкурска гариза бирүчеләр һәм Конкурста катнашучылар

5.1. Конкурста ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар, шул исәптән СЮ КБО да катнаша ала.

Конкурска гариза бирүчеләр булып әлеге Нигезләмәнең 6.4 нче пункты нигезендә документлар пакеты тапшырган ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар һәм СЮ КБО (алга таба – Гариза бирүчеләр) тора.

Конкурста катнашучылар булып әлеге Нигезләмәнең 7.1 – 7.4 нче пунктлары нигезендә конкурс эшләре Конкурста катнашуга кертелгән ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, авторлар коллективлары һәм төркемнәре, шулай ук башка юридик затлар һәм СЮ КБО (алга таба – Катнашучылар) тора.

5.2. Конкурска тәкъдим ителгән конкурс эше бер, шулай ук ике яки берничә зат тарафыннан башкарылган булырга мөмкин.

## 6. Конкурсны үткәрү шартлары

6.1. Оештыручы Конкурс үткәрү турындагы карарны аны үткәрү көненә кадәр 60 календарь көннән дә соңга калмыйча кабул итә. Оештыручы, әлеге карарны кабул иткәннән соң, җиде календарь көн эчендә Конкурс турындагы мәгълүматны Оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар» һәм «Конкурслар» дигән ике бүлектә урнаштыра, ул үз эченә Оештыручының Конкурс үткәрү хакында карар кабул иткән көнен, Конкурсны үткәрү көнен, вакытын һәм урынын, Конкурска документлар пакетын кабул итә башлау һәм аны тәмамлау көнен һәм вакытын; Конкурска тәкъдим ителгән документларны карап тикшерү чорын һәм Конкурсның йомгакларын ясау көнен; җиңүчеләрне бүләкләү көнен, вакытын һәм урынын ала.

6.2. Әгәр Конкурска бер генә заявка тапшырылса яки бер заявка да тапшырылмаса, Конкурс үткәрелмәгән булып санала.

6.3. Конкурсны Оештыручыга әлеге Нигезләмәнең 6.1 нче пункты нигезендә урнаштырылган мәгълүматта күрсәтелгән вакыт эчендә Конкурсны игълан иткән көнгә кадәр бер ел дәвамында Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә бу Нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән Конкурсның өстенлекле юнәлешәренең берсе буенча эшләнгән конкурс эшләре тапшырыла.

6.4. Конкурска конкурс эшләренең түбәндәге төрләре кабул ителә:

MP4 һәм (яки) күчереп алу өчен актив сылтама форматында CD- яки DVD-дискта һәм (яки) флеш-картада кертелгән кимендә 15 секунд дәвамлылыкта телевидение эшләре (программалар, махсус репортажлар, телесюжетлар цикллары һәм башка телевидение эшләре);

MP4 һәм (яки) күчереп алу өчен актив сылтама форматында CD- яки DVD-дискта һәм (яки) флеш-картада кертелгән кимендә 15 секунд дәвамлылыкта радиосюжетлар (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар цикллары);

җитәкче имзасы һәм юридик зат мөһере (булганда) белән яисә физик затлар өчен автор имзасы белән таныкланган, кимендә 500 билгедән торган, төп нөсхәдә, һәм (яки) күчермәдә, һәм (яки) сканлаштырылган вариантта кертелгән басма массакүләм мәгълүмат чараларында (язмалар серияләре, махсус чыгарылышлар) газеталарда (журналларда, альманахларда) һәм башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында язмалар;

язмага актив сылтаманы һәм (яки) күчереп алу өчен актив сылтаманы күрсәтеп, бастырып чыгарып, яки CD-, яки DVD-дискта, яки флеш-картада кертелгән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә язмалар.

6.5. Конкурска кертелгән конкурс эшләре рецензияләнми.

6.6. Конкурста катнашу өчен Гариза бирүчеләр түбәндәге документлар пакетын тапшыра:

1) әлеге Нигезләмәнең 6.4 нче пунктында күрсәтелгән форматта конкурс эше;

2) әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча катнашуга анкета-заявка (төп нөсхәсе, күчермәсе яки PDF-файл форматында сканлаштырылган варианты);

3) юридик затлар, шул исәптән Татарстан Республикасының СЮ КБО, юридик затлар буларак теркәлгән ММЧ редакцияләре өчен түбәндәге документлар:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында шаһәдатнамә (салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны) (күчермәсе);

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә (Төп дәүләт теркәү саны) (күчермәсе);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләү турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермәсе);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (документларны Конкурска тапшырган көнгә кадәр күп дигәндә 6 ай алдан бирелгән);

ММЧ теркәү турында шаһәдатнамә (күчермәсе) – ММЧ өчен;

4) физик затлар өчен (авторлар, авторлар коллективлары):

паспорт яки аны алыштыра торган документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, бирүгә һәм таратуга ризалык;

5) юридик зат булмаган ММЧ редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында шаһәдатнамә (күчермәсе);

ММЧ редакциясе уставының яки «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алыштыра торган шартнамәнең күчермәсе, әгәр ММЧ редакциясендә 10 кешедән әзрәк кеше булса;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан тиешле массакүләм мәгълүмат чарасына кагылышлы өземтә (документларны Конкурска тапшырган көнгә кадәр күп дигәндә 6 ай алдан бирелгән);

тиешле массакүләм мәгълүмат чарасын салым органында исәпкә кую турында шаһәдатнамә күчермәсе (салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны);

баш мөхәррирне вазыйфага билгеләү турында боерык күчермәсе;

6) авторлар яки авторлар коллективлары яисә төркемнәре, яки юридик затлар, яки ММЧ редакцияләре, яки СЮ КБО өчен:

конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта, процентлар чагыштырмасында акчаны бүлү турында килешү.

Әлеге пунктның 2 – 6 пунктчаларында күрсәтелгән документларны кәгазьдә яки электрон вариантта, сканлаштырып, PDF-файл форматында бирү рөхсәт ителә.

6.7. Әлеге Нигезләмәнең 6.6 нчы пункты нигезендә документлар исемлеге, Оештыручы Конкурс үткәрү турында карар кабул иткән көннән соң, 30 календарь көн эчендә «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс» билгесе белән 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 нче йорт адресы буенча кулга бирелә, почта аша яки konkurs.nko@tatar.ru электрон почтасы аша Оештыручы тарафыннан кабул ителә, белешмәләр өчен тел.: 8(843) 570-31-04.

6.8. Конкурска тапшырылган документлар пакеты, аны Гариза бирүчедән алган көннән соң, бер эш көне эчендә Оештыручы тарафыннан теркәлә.

6.9. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һәм башка) Гариза бирүчеләр һәм Катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

6.10. Конкурс йомгаклары Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс эшләрен кабул итү тәмамланган көннән соң 30 календарь көн эчендә ясала һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия утырышын үткәргән көннән соң өч календарь көн эчендә комиссия рәисе яки анын урынбасары тарафыннан имзалана.

6.11. Конкурска тапшырылган документлар Катнашучыларга бары тик аларның таләбе буенча конкурс эшен кайтару турында Катнашучының таләбен алган көннән соң 20 календарь көн эчендә кире кайтарыла.

6.12. Конкурс эшләре Конкурс йомгакларын ясаган көннән соң өч ел дәвамында саклана.

## 7. Конкурс эшләрен Конкурска кертү критерийлары

7.1. Конкурс эшен Конкурста катнашуга кертү стадиясендә Оештыручы, Гариза бирүченең документлары кабул ителгән көннән соң, өч эш көне эчендә конкурс эшләренең түбәндәге таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләү нәтиҗәләре буенча Конкурска кертү яки кертүдән баш тарту хакында карар кабул итә:

әлеге Нигезләмәнең 6.3, 6.4, 6.6, 6.7 нче пунктларында бәян ителгән таләпләр нигезендә тапшыру;

әлеге Нигезләмәнең III бүлегендәге Конкурсның өстенлекле юнәлешләре нигезендә тапшыру.

7.2. Конкурста катнашуга кертүдән баш тарту өчен нигез булып конкурс эшенең әлеге Нигезләмәдәге 7.1 нче пунктта күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве тора.

7.3. Конкурс эшенең Конкурста катнашуга кертелүе турында һәм аны кертүдән баш тарту хакында Гариза бирүчеләргә, анкета-заявкада күрсәтелгән адрес буенча илтеп тапшыру турында хәбәр итеп, Оештыручы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) имзалаган һәм Конкурста катнашуга кертү турында яки кертүдән баш тарту хакында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә җибәрелгән заказлы хат аша хәбәр ителә.

7.4. Конкурска кертелмәгән конкурс эшләре, документларны Конкурска тапшыру өчен билгеләнгән вакыт эчендә җитешсезлекләрне бетергәннән соң, конкурска яңадан тәкъдим ителә ала.

## 8. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

8.1. Конкурска кертелгән конкурс эшләрен бәяләгәндә, түбәндәге критерийлар файдаланыла:

Конкурс тематикасын һәм юнәлешләрен чагылдыра торган эчтәлек (0 – 10 балл);

сәнгати алымнар куллану (0 – 10 балл);

язмаларның һәм сюжетларның Татарстан Республикасы халкы өчен тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте (0 – 10 балл);

концепциянең, сценарийның һәм билгеләнгән тематиканы яктыртуга якын килү юлының оригинальлеге (0 – 10 балл);

Татарстан Республикасының СЮ КБО вәкилләрен материалда катнашуга җәлеп итү (0 – 10 балл);

Татарстан Республикасының СЮ КБО турында материаллар сериясе (ике һәм күбрәк) булу (0 – 10 балл).

8.2. Балларның чик суммаларын призлы урыннар буенча бүлү:

1 урын: 60 – 50 балл.

2 урын: 49 – 40 балл.

3 урын: 39 – 30 балл.

## 9. Конкурс комиссиясе

9.1. Конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

9.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез нигездә башкара.

9.3. Комиссия эше утырышлар рәвешендә гамәлгә ашырыла. Утырышта конкурс комиссиясе әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, ул хокуклы санала.

9.4. Конкурс комиссиясе эше белән рәис җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, конкурс комиссиясе рәисе вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

9.5. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе утырышларын үткәрү урынын, көнен һәм вакытын билгели, конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә һәм конкурс комиссиясе секретаренә конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү мәсьәләләре буенча йөкләмәләр бирә.

9.6. Конкурс комиссиясе әлеге Нигезләмәнең 8.1 нче пунктында билгеләнгән конкурс эшләрен бәяләү критерийлары нигезендә тапшырылган эшләрне бәяли.

9.7. Конкурска нәтиҗәләр ясаганда, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) призлы урыннар бирү турында һәм Оештыручыга акчалата бүләкләрне түләү хакында рекомендация бирү турында;

б) әгәр тапшырылган эшләрнең берсе дә игътибарга лаек дип танылмаган булса яки аларның берсе дә әлеге Нигезләмәдә бәян ителгән таләпләргә җавап бирмәсә, бер яки берничә номинация буенча призлы урыннар бирмәү һәм аерым номинацияләргә акчалата бүләкләү бирү турында;

в) әгәр конкурс үткәрелмәгән булып саналса, гомумән, призлы урыннар һәм акчалата бүләкләү бирмәү турында.

9.8. Әгәр берәр номинациягә бер генә заявка тапшырылса яки бер заявка да тапшырылмаса, номинация булмаган дип санала, һәм әлеге номинация буенча призларга бүлеп бирелгән акча тигез өлешләрдә башка номинацияләр арасында бүленә.

9.9. Конкурс комиссиясе номинацияләрнең берәрсендә урын(нар) бирмәү турында карар кабул итсә, призларга бүлеп бирелгән акча оештыручы тарафыннан

тигез өлешләрдә башка номинацияләрдә шул ук урыннарны алган җиңүчеләр арасында бүленә.

9.10. Призлы урын бирелгән бер конкурс эшендә берничә автор һәм (яки) берничә юридик зат һәм (яки) берничә ММЧ редакциясе катнашса, конкурс комиссиясенә тапшырылган алар төзегән килешү нигезендә бу номинация урынына билгеләнгән призларга бүлеп бирелгән акча әлеге затлар арасында бүленә.

9.11. Конкурс комиссиясе карары нигезендә ике яки берничә катнашучыга призлы урын бирү теләсә нинди номинациядә баллар тигез булган очракта мөмкин.

9.12. Конкурс комиссиясе әгъзаларының утырышында мәсьәләләрне хәл иткәндә һәр конкурс комиссиясе әгъзасы бер тавышка ия. Бер конкурс комиссиясе әгъзасының тавышын башкага бирү рөхсәт ителми.

9.13. Конкурс комиссиясе утырышын кимендә әгъзаларының яртысы булганда үткәрә. Конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының, конкурс комиссиясе рәисе һәм аның урынбасарларының тавышлары күпчелеге нигезендә кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9.14. Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисенең яки аны алыштыручы затның тавышы хәлиткеч була.

9.15. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясенең әгъзалары составына керми һәм аның утырышында тавыш бирүгә хокуксыз катнаша.

9.16. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе ачык файдаланууда Оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында беркетмәне имзалаганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

## 10. Конкурсның приз фонды

10.1. Конкурсның гомуми приз фонды 400,0 мең сум тәшкил итә.

10.2. Конкурста җиңүчеләргә түбәндәге акчалата бүләкләр бирелә:

<table>
<tr><th>Номинацияләр</th><th>Урын</th><th>Сумма, мең сум</th></tr>
<tr><td rowspan="3">«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы телесюжет (яки телетапшыру)»</td><td>I урын</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>II урын</td><td>30,0</td></tr>
<tr><td>III урын</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td rowspan="3">«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча иң яхшы радиосюжет (яки радиотапшыру)»</td><td>I урын</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>II урын</td><td>30,0</td></tr>
<tr><td>III урын</td><td>20,0</td></tr>
<tr><td rowspan="2">«Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар</td><td>I урын</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>II урын</td><td>30,0</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| эшчәнлеген яктырту буенча басма массакүләм-мәгълүмат чараларында иң яхшы язма» | III урын | 20,0 |
| «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген яктырту буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә иң яхшы язма» | I урын | 50,0 |
| | II урын | 30,0 |
| | III урын | 20,0 |

10.3. Конкурста җиңүчеләргә әлеге Нигезләмәдәге 9.8 нче – 9.10 нчы пунктлар нигезендә бу Нигезләмәнең 10.2 нче пунктында күрсәтелгән күләмдә бер-берсеннән аерылган акчалата бүләкләр бирелә.

10.4. Конкурсның приз фондын бүлү һәм документларны Конкурска тапшырганда анкета-заявкада күрсәтелгән кредит оешмасындагы счетларга акчаны күчерү Конкурс комиссиясе карары һәм бу Нигезләмә нигезендә конкурс комиссиясе конкурска йомгаклар ясаган көннән соң 30 календарь көн эчендә Оештыручы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 11. Махсус шартлар

11.1. Оештыручы Россия Федерациясе Граждан кодексында күздә тотылган тәртиптә Конкурс эшләрен тапшыру өчен билгеләнгән вакытның беренче яртысында Конкурсны үткәрмәү хокукын үзендә калдыра.

11.2. Конкурс эшләрен тапшырган Гариза бирүчеләр һәм Катнашучылар өченче затларның авторлык хокукларын сакламаган өчен законнар нигезендә җавап тота.

F:\KARAR\2016\885_1.docx

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурста катнашуга
анкета-заявка

Гариза бирүче (юридик зат (оештыру-хокукый формасы һәм исеме) / физик зат (Ф.И.Ат.ис. (булганда):

Авторның (авторларның) Ф.И.Ат.ис. (булганда): ____________________________________________

Өстенлекле юнәлеш һәм номинация исеме: ____________________________

Конкурс эшенең исеме: ____________________________________________

Кыскача аннотация: ____________________________________________

Кәрәзле телефоны: ____________________________________________

Эш телефоны: ____________________________________________

E-mail: ____________________________________________

Конкурс йомгаклары буенча бирелгән акчаны күчерү өчен, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет реквизитлары:

____________________________________________

(Юридик затлар өчен: җитәкченең Ф.И.Ат.ис. (булганда), имзасы, оешма мөһере (булганда); физик затлар өчен: гариза бирүченең Ф.И.Ат.ис. (булганда), имзасы)

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, бирүгә һәм таратуга ризалык
(физик затлар тарафыннан тутырыла)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурсны оештыручыга – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына шәхси мәгълүматларымны түбәндәге күләмдә эшкәртүгә, бирүгә һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки теләсә нинди өченче затлардан алуны кертеп) ризалыгымны белдерәм:

| | |
|---|---|
| Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге | (Ф.И.Ат.ис, җенесе, туган көне һәм урыны, гражданлыгы, шәхесне таныклый торган документ реквизитлары (документның төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлгән урын, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет турында белешмәләр) |

__________________________________________________________
(Ф.И.Ат.ис. (булганда), имза)

__________________________
(Дата)

F:\KARAR\2016\885_2.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Пономарев Кирилл Николаевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча), конкурс комиссиясе рәисе |
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары |
| Гарифуллина Регина Рафаэль кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының ММЧ белән эшләү идарәсе башлыгы, конкурс комиссиясе секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтҗанов Ислам Галиәхмәт улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Агеева Любовь Владимировна | «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ» югары белем бирә торган федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе Социаль технологияләр институтының тарих һәм җәмәгатьчелек белән элемтә кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Беляков Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бикчәнтәева Ләлә Дмитриевна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәдәният һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Гарифуллин Васил Заһит улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең массакүләм коммуникацияләр бүлеге җитәкчесе, Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге Президиумы әгъзасы (килешү буенча) |
| Киркина Нина Николаевна | Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге Президиумы әгъзасы (килешү буенча) |
| Латыйпова Венера Зиннәт кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең гамәли экология кафедрасы мөдире, экология контроле лабораториясе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Максимова Маргарита Николаевна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эксперты, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары һөнәри белем бирә торган федераль дәүләт мәгариф учреждениесенең социаль эш факультеты деканы, икътисадый теория һәм социаль эш кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Сәгыйтов Инсар Сәгыйть улы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы |
| Тузиков Андрей Римович | «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары белем бирә торган федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең дәүләт, муниципаль идарә һәм социология кафедрасы мөдире, сәнәгать сәясәте һәм бизнес-идарә итү факультеты деканы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шәйхетдинова Светлана Каим кызы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирә торган федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институтының журналистика кафедрасы мөдире (килешү буенча). |

______________________________________